**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ**
**КОМИТЕТ**
422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

КАРАР

23 нче август 2019 ел. № 251

Әтнә муниципаль районы үзәгеннән – Олы Әтнә авылыннан 11 километр ераклыкта урнашкан Әтнә муниципаль районының ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына беренче чиратта кирәкле товарлар китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнарын өлешчә каплау өчен Әтнә муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында "

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы составына керүче, ерак торак пунктларда яшәүче авыл халкын беренче чиратта кирәкле товарлар белән тәэмин итү, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2017 ел, 20 ноябрь, 887 нче номерлы “Татарстан Республикасы район үзәкләреннән 11 км. ераклыкта урнашкан һәм аз халыклы авыл пунктларына иң беренче чиратта кирәк булган товарларны китерү белән бәйле ,кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарын өлешчә каплау өчен,Татарстан Республикасы бюджетыннан, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең бюджетларына, башка төр бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында»гы карарын үтәү максатларында ,Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты, карар бирә:

1. Расларга:

- Әтнә муниципаль районы үзәге – Олы Әтнә авылыннан 11 километр ераклыкта урнашкан Әтнә муниципаль районының ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына беренче чиратта кирәкле товарлар китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнарын өлешчә каплау өчен , Әтнә муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен (1 нче кушымта);

- Субсидия алу хокукына дәгъва кылучы юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне, физик затларны сайлап алуны гамәлгә ашыручы комиссия составын (2 нче кушымта).

2.Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче А.Ф. Каюмов